# КАРАР № 46

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге Советы утырышы

17 август 2022 ел Түбән Көек авылы

**Түбән Көек авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 104 номерлы карары белән расланган “Түбән Көек авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керү сәбәпле һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләп (2022 елның 14 мартына үзгәрешләр керү белән бәйле), 2021 нче елның 29 нчы ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Түбән Көек авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 104 номерлы карары белән расланган "Түбән Көек авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 16 статьяның 13 абзацында "муниципаль гарантияләр буенча" сүзләрен "муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 16 статьяның 17 абзацында “күрсәтелгән муниципаль гарантияләр буенча” сүзләрен “муниципаль гарантияләрдән килеп чыгучы” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Д.М. Галиәхмәтов